КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 ноябрь г.Казань № 1220

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыру нормативларын, дәвалап бетерү (тернәкләндерү) дәвамлылыгы нормативларын раслау турында» 2022 ел, 1 сентябрь, 941 нче карары белән расланган 2023 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга норматив чыгымнарга үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыру нормативларын, дәвалап бетерү (тернәкләндерү) дәвамлылыгы нормативларын раслау турында» 2022 ел, 1 сентябрь, 941 нче карары белән расланган 2023 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне

(тернәкләндерүне) оештыруга норматив чыгымнарга, аларны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 1 сентябрь, 941 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 16 сентябрь, 1220 нче
карары редакциясендә)

2023 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга норматив чыгымнар

| Т/с | Дәвалап бетерү (тернәкләндерү) юнәлешенең исеме | Норматив чыгымнар, койка көненә сум |
|---|---|---|
| 1. | Миокардның кискен инфарктын, тотрыксыз стенокардияне, стационарда дәваланганнан соң, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларына операцияләрдән соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 502,57 |
| 2. | Баш миенең кан әйләнеше кискен бозылуын стационар дәвалаудан соң ук дәвалау (тернәкләндерү) | 1 495,35 |
| 3. | Умыртка сөяге үсешендә кимчелекләр һәм авырулар булганда, буыннарга пластика куйганда, очлыкларны эндопротезлаганда һәм реэндопротезлаганда, реплантацияләгәндә ортопедик, травматологик операцияләрдән соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 476,07 |
| 4. | Риск төркемнәрендәге йөкле хатын-кызлар авыруларын, стационарда дәваланганнан соң, турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 473,55 |
| 5. | Шикәр диабетын, стационарда дәваланганнан соң, турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 468,75 |

_______________________